**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСЧАНО-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422625 с. Песчаные Ковали,
ул. Октябрьская,д.9а
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАИШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОМЛЫ КОВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422625 с. Комлы Ковал авылы,
ул. Октябрьск урамы, 9 а нчы йорт,
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

---

**2026елның 17 феврале** **3 номер**

# КАРАР

## Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, тирә-як мохитен саклап калу, территорияләрне планлаштыру, физик һәм юридик затларның хокукый һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясындагы 4 пункты, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән, карар бирәм:

1. 16:24:090102:928 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә махсуслаштырылган төзүче "Яңа Ковал" ҖЧЖеннән "кибетләр"гә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар үткәрү чорын – кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә.

3. 16:24:090102:928 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән файдалануның "Яңа Ковал» махсуслаштырылган төзүче” ҖЧЖнең «кибетләр"гә шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны оештыруда һәм уздыруда әзерлек үткәрергә.

1.1. Гавами тыңлаулар башлану турында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 маддәсендә каралган хәбәр әзерләргә;

1.2. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көннән алып ике эш көне эчендә Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә, карар кабул итү өчен документлар комплекты кушып, хәбәр итәргә кирәк..

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **А.Ф. Миндубаев**